РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ**
**Уразлинского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Мира, 7,с. Уразлино, 422838
тел. (884377)33-2-31, факс: (884377) 33-2-31
ОКПО 94304522, ОГРН 1061672020497
ИНН/КПП 1622004732/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Уразлы**
**авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

Тынычлык урамы, 7,Уразлы авылы, 422838,
тел. (884377)33-2-31, факс: (884377) 33-2-31
ОКПО 94304522, ОГРН 1061672020497
ИНН/КПП 1622004732/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**28 ноябрь 2019 года** **№ 49**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Уразлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2019 елның 10 декабрендә 09 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Уразлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясе, Уразлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

* Җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;

* Кышкы юлларны карап тоту;

* Чүп үләннәрен чабу;

* Күмү урыннарын карап тоту һәм ремонтлау ;

"ӘЙЕ" "ЮК"

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга) :

- ТР, Кама Тамагы районы, Уразлы авылы, Тынычлык урамы, 7;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Карамалы авылы, Кече урамы, 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Салтыган авылы, Урта урамы, 1,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Уразлы авыл җирлеге**
**башлыгы** **М.Г.Хәмидуллин**